**МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**22.11.2024** г. Казань **2615**

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 14.11.2023 ел, № 2707 боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан карар кабул итү тәртибенә үзгәреш кертү турында

Боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 14.11.2023 ел, № 2707 «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан карар кабул итү тәртибен раслау турында»гы боерыгы (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 23.09.2024 № 2122 боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 пунктта:

икенче абзацта «бюджет хисаплылыгыннан өземтә» сүзләрен «белешмә» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацны «,Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160 $^{1}$ статьясы нигезендә билгеләнгән бюджетка түләүләр, пенялар һәм алар буенча штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү буенча бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Регламентында каралган» сүзләре белән тулыландырырга;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«амнистия турындагы акт яисә штраф рәвешендәге җәзага хөкем ителгәннәргә карата ярлыкау акты яисә суд акты рәвешендә ярлыкау турында акт, аңа ярашлы рәвештә бюджет керемнәре администраторы Бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеген югалта, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә (Тәртипнең 2 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән очракта)»;

түбәндәге эчтәлекле ундүртенче абзац өстәргә:

«гражданның судтан тыш банкротлыгы процедурасын тәмамлау турында банкротлык турында Белешмәләрнең бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ (Тәртипнең 2 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән очракта).».

Министр М.М.Миңнуллин